ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31 октября 2025г. № 8921

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучылар һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр өчен өстәмә социаль ярдәм чаралары турында» 2025 елның 23 гыйнварындагы 361 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучылар һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр өчен өстәмә социаль ярдәм чаралары турында» 2025 елның 23 гыйнварындагы 361 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2025 елның 9 июнендәге 4118 номерлы, 2025 елның 4 июлендәге 4907 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 9 пунктча өстәргә:

«9) Сириядән килгән, шул исәптән Россия территориясендә вакытлыча яшеренү урыны алган, Яр Чаллы шәһәрендә вакытлыча урнаштырылган качакларның балалары өчен: 1-4 сыйныфлар өчен бер укучыга туклану бәясе – 128,90 сум; 5-11 сыйныфлар өчен – 130,88 сум»;

2) 3 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 8 пунктча өстәргә:

«8) Сириядән килгән, шул исәптән Россия территориясендә вакытлыча яшеренү урыны алган, Яр Чаллы шәһәрендә вакытлыча урнаштырылган качак балаларының ата-аналарын.»;

3) 1 нче кушымтада:

- 3 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 9 пунктча өстәргә:

«9) Сириядән килгән, шул исәптән Россия территориясендә вакытлыча яшерену урыны алган, Яр Чаллы шәһәрендә вакытлыча урнаштырылган качакларның балалары өчен.»;

- 9 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзацлар өстәргә:

«- Сириядән килгән, шул исәптән вакытлыча яшерену урыны статусында Россия территориясендә булган, Яр Чаллы шәһәрендә вакытлыча урнаштырылган качакларның балалары өчен:

качак таныклыгы яки Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча яшерену урыны биру турында таныклык күчермәсе.»;

4) 2 нче кушымтада:

- 2 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 8 пунктча өстәргә:

«8) Сириядән килгән, шул исәптән Россия территориясендә вакытлыча яшерену урыны алган, Яр Чаллы шәһәрендә вакытлыча урнаштырылган качак балаларның ата-аналарына.»;

- 5 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзацлар өстәргә:

«- Сириядән килгән, шул исәптән Россия территориясендә вакытлыча яшерену урыны алган, Яр Чаллы шәһәрендә вакытлыча урнаштырылган качакларның балалары өчен:

качак таныклыгы яки Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча яшерену урыны биру турында таныклык күчермәсе.».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов